МЭР ГОРОДА
НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
ХАКИМЕ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15 июнь 2021ел. № м. 236

Цифрлы финанс активлары һәм цифрлы хокуклар турында мәгълүматлар тапшыру хакында

Россия Федерациясе Президентының «Цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законның аерым нигезләмәләрен тормышка ашыру чаралары хакында» 2020 елның 10 декабрендәге 778 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Президентының «Цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законның аерым нигезләмәләрен тормышка ашыру чаралары һәм коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 3 июнендәге 427-ПУ номерлы Указы нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, шулай ук Шәһәр Хакименең «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар, шулай ук Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирү турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2014 елның 21 ноябрендәге 692 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфалары исемлегендә каралмаган муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче һәм әлеге исемлектә каралган муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы муниципаль хезмәткәрләр Россия Федерациясе Президентының «Керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмә формасын раслау һәм Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 елның 23 июнендәге 460 номерлы Указы белән расланган белешмә формасы буенча бирелә торган мәгълүматлар белән бергә Татарстан Республикасы Президентының «Цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законның аерым нигезләмәләрен тормышка ашыру чаралары һәм коррупциягә

каршы тору мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 3 июнендәге 427-ПУ номерлы Указына 1 нче кушымтада каралган форма буенча аларныкы, хатыныныкы (иренеке) һәм балигъ булмаган балаларыныкы булган, бер үк вакытта цифрлы финанс активлары һәм башка цифрлы хокукларны үз эченә алган цифрлы финанс активлары һәм цифрлы хокуклар, утилитар цифрлы хокуклар һәм цифрлы валюта (алар булганда) турында белдерү кәгазе тапшыруны билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында каралган белдерү кәгазе тиешле вазыйфаны биләү өчен документлар тапшыру аеннан алдагы айның беренче числосына торыш буенча тапшырыла.

3. Әлеге карар 2021 елның 30 июненә кадәр гамәлдә.

4. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны муниципаль берәмлек Башлыгы урынбасары И.А. Сәгыйдуллинага, Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.Ш. Салаховка, Контроль-хисап палатасы рәисе Т.В. Шливега йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев